ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының 2019 елның сентябреннән 2024 елның февраленә кадәрге эш чоры өчен хисабы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетының 2019 елның сентябреннән 2024 елның февраленә кадәрге эш чоры өчен хисабын, эшчәнлегенең нәтиҗәле булуын билгеләп, игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Үз эшчәнлеге юнәлешләре буенча эшләүне Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатлары, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советының һәм Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының профильле комитетлары, Россия Федерациясе субъектлары закон чыгару органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре вәкиллекле органнары комитетлары (комиссияләре) белән үзара эшчәнлектә дәвам итәргә.

2.2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативаларын һәм мөрәҗәгатьләрен карауны контрольдә тоту өлешендә Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы, Россия Федерациясе Хөкүмәте белән үзара эшчәнлекне арттырырга.

2.3. Татарстан Республикасы законнарын үз вакытында актуальләштерү максатында аларны мониторинглауны дәвам итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы Ю.З. Камалтынов

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы аппараты. Аппарат Государственного Совета Республики Татарстан. Беркетмә бүлеге. Протокольный отдел

Казан шәһәре,
2024 елның 29 марты
№ 2412-VI ДС